РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 1 сентябре № 38

**Түбән Кама шәһәр Советының 2012 елның 20 апрелендәге 17 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәр Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2012 елның 20 апрелендәге 17 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәр Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокукы булган Россия Федерациясе гражданлыгын яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе катнашучысы булган чит ил гражданлыгын туктату, чит ил гражданлыгы (гражданлыгында булу) яисә тору кәгазе яки Россия Федерациясе гражданының яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданының чит ил территориясендә даими яшәүгә хокукын раслаучы башка документның булуы, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин